Фәнни мәкаләдә бәяләү объекты – Әхтәм Зарипов тарафыннан эшләнгән «Хәтәр һәм хәтер» телевизион фильмы һәм Ә. Еникинең «Бер генә сәгатькә» исемле киносценарие. Тикшерү предметы булып язучы һәм режиссер тәкъдим иткән текстларның идея-эстетик сыйфатлары, сәхнәләштерү үзенчәлекләре, әсәрләрдәге тирән фәлсәфи-әхлакый фикерләрнең тамашачыга җиткерелү алымнары тора. Шулай ук телефильмда төп һәм аларны ачарга ярдәм иткән икенчел дәрәҗәдәге персонажларны башкарган актерлар, аларның осталыгы мәсьәләләре дә гыйльми язманың тикшерү предметын һәм яңалыгын билгели.

**Төп төшенчәләр**: татар әдәбияты, мәдәният, Әмирхан Еники, Әхтәм Зарипов, хикәя, телевизион фильм

**Сылтама өчен:** Мөхәммәдиева С.Ф., Гайнуллина Г.Р. Әмирхан Еники әсәрләре кино сәнгатендә («Хәтәр һәм хәтер» телефильмы мисалында) // Tatarica. 2025. № 1 (24). 96–109 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-96-109

## Кереш

Татар әдәбияты классигы Әмирхан Еники иҗаты һәрдаим әдәбият һәм сәнгать әһелләренең игътибарын җәлеп итә. Язучының күп кенә әсәрләре бүгенге көндә театр һәм кино сәнгатендә уйнала. Әдип иҗатының театр сәнгате теленә күчерелүе, аерым алганда, соңгы дүрт дистә ел эчендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Әлмәт Татар дәүләт драма театры, Казан федераль университетының «Мизгел» студентлар театрында сәхнәләштерелүе әдәбият галимнәре тарафыннан бәяләнә килә [1]. Язучының әсәрләре Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрында да сәхнәләштерелде. 2024 нче елда язучының «Әйтелмәгән васыять» хикәясе мотивларын файдаланып, «Матурлык» спектакле (режиссер Егор Чернышев, инсценировка авторы Булат Минкин) тәкъдим ителә. 2025 нче елның ноябрендә шушы ук театр сәхнәсендә язучының «Гөләндәм туташ хатирәсе» әсәре мотивлары нигезендә шул исемдәге спектакль (режиссер Виктория Печерникова, инсценировка авторы Айдар Әхмәдиев) куела.

Театр белән кардәш кино һәм телевизион фильмнар сәнгате аша иҗатны пропагандалау мөмкинлеге шактый киң. Әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор Ф.Г. Галимуллин «Әмирхан Еники әсәрләренең һәрберсе – үзе бер нәфис фильм», – дип әйтә [2]. XXI гасыр башында Ә. Еники прозасы кино сәнгатенә дә үтеп керә. 2000-2001 нче елларда «Илһамият» киностудиясе Ә. Еникинең «Бер генә сәгатькә», «Кунакчыл домшан», «Тауларга карап» хикәяләре мотивлары нигезендә режиссер һәм инсценировка авторы Әхтәм Зарипов тарафыннан эшләнгән телевизион нәфис фильмны тәкъдим итә. Әйтергә кирәк, бу фильмда Ә. Еникинең «Ана һәм кыз» хикәясеннән һәм «Без дә солдатлар идек» дип исемләнгән автобиографик повестеннан алынган мотивлар тоемлана.

Язучының әсәрләре сәхнәләштерү, фильм итеп төшерү өчен шактый катлаулы икәнен дә билгеләп үтү зарур. Бүгенге көндә Ә. Еникинең Бөек Ватан сугышы (1941-1945) темасына караган прозасының үзенчәлекләре, татар кино сәнгате үсешендә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхтәм Зариповның (1935-1924) роле, әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинованың яңа фикер-карашлары, хезмәтләре игътибарга лаек [3; 4]. Галимә ассызыклаганча, Ә. Еники иҗатында «психологизм бик көчле, шуңа күрә, драматик яссылыкка чыгару өчен, режиссер һәм сценарист тарафыннан бик күп хезмәт сорала» [2]. 2024 нче елда Әмирхан Еникинең «Матурлык», «Бер генә сәгатькә», «Кем җырлады?» хикәяләрендәге мотивлар нигезендә «823 нче километр» исемле кинофильм (сценарий авторы Валерия Байкеева, режиссерлары Ирек Хафизов, Әмир Галиәскәров) тәкъдим ителә. Әмма фильм әдәбият галимнәре тарафыннан шактый тәнкыйтьләнә, Ә. Еники әсәрләренә хас булган стиль җуелган, дигән карашлар җиткерелә [2].

**Тикшеренү материаллары һәм методлары**

Фәнни тикшеренү материалы буларак Ә. Еникинең «Бер генә сәгатькә» (1944), «Кунакчыл дошман» (1945), «Тауларга карап» (1948) хикәяләре һәм алар нигезендә эшләнгән «Хәтәр һәм хәтер» телевизион нәфис фильмы (сценарий авторы һәм режиссер Әхтәм Зарипов), Ә. Еникинең «Бер генә сәгатькә» киносценарие [5] алынды.

Тикшеренү методлары һәм принциплары гыйльми эзләнүнең максатына һәм өйрәнү объектына нигезләнеп сайланылды. Әдәби иҗатны, әсәрне шәрехләү һәм анализлауның мәдәни-тарихи, чагыштырма-тарихи методлары файдаланылды.

**Фикер алышу**

Кино сәнгате теленә Ә. Еникинең башлыча Бөек Ватан сугышы елларында һәм аннан соң сугыш темасына мөнәсәбәтле әсәрләре күчерелә. Әйтергә кирәк, сәнгатьнең бу төре Ә. Еникигә якын, чөнки 20-30 нчы елларда татар язучыларының Мәскәү киностудиясе белән хезмәттәшлек иткәнлеге мәгълүм [7]. Әдипнең 1931-1937 нче елларда Казанда Хезмәтне фәнни оештыру институтында психотехник белгечлеге алуы, 1935-1936 нчы еллар аралыгында кинофиксация трестында инструктор булып хезмәт куюы һәм 1936-1937 нче елларда Бакуда «Азеркино» киностудиясендә районнан махсус җибәрелгән вәкил булып торуы мәгълүм. Язучының «Бер генә сәгатькә» (1944) хикәясе буенча киносценарий эшләп [5], 1970 нче елда дөньяга чыгаруы да игътибарга лаек [7, б. 12-14].

М. Хәбетдинова Ә. Еники иҗатында Бөек Ватан сугышы темасы чагылышын аерым игътибарга алып өйрәнә: «1972 нче елда «Фронт көндәлекләре» исеме астында Ә. Еникинең «Без дә солдатлар идек» дип аталган автобиографик повесте дөнья күрә» [3, б. 207]. Галимә язучының сугыш елларында язылган «Фронт көндәлекләре»нең «Казан утлары» журналына 1994 нче елда үзгәртелгән вариантта тәкъдим ителүен ассызыклый, кульязма белән журнал вариантын чагыштырып, этрафлы бәя бирә [3, б. 204-211].

Әдипнең 1944-1948 нче елларда язылган өч хикәясе («Бер генә сәгатькә», «Кунакчыл дошман», «Тауларга карап») 2000-2001 нче елларда эшләнгән «Хәтәр һәм хәтер» телевизион фильмының нигезенә ята һәм 1944-1964 еллар аралыгында язылган хикәяләре («Бер генә сәгатькә», «Кем җырлады?», «Матурлык») 2024 нче елны дөньяга чыгарылган «823 нче километр» кинофильмының төп эчтәлеген тәшкил итә.

«Хәтәр һәм хәтер» телефильмы – ике сәгать ярымлык өч серияле нәфис фильм. Бирелә Бөек Ватан сугышында һәлак булган кинооператорлар төшергән «Билгесез солдат» һәм «Ватан сакчылары» фильмнарыннан фрагментлар файдаланылган.

Фильмның башлам өлеше язучының «Бер генә сәгатькә» киносценариеның башлам өлешенә тәңгәл. Сугыш башланган вакыт сурәте нәкъ Ә. Еникидәгечә тәкъдим ителә: «Җәй. Печән өсте. Инде арыш та өлгереп килә. Биек, аяз күк. Кырлар өстендә ялгыз тургай талпынып сайрый. Бераздан аның сайравы әкрен генә моңлы бер көйгә әверелеп ишетелә башлый» [5, б. 1]. Мәрьям абыстайның улларын зарыгып көтүе, бигрәк тә сугыш башланыр алдыннан гына армия сафларына алынып, әлегә хәбәре булмаган Гомәр улы турында борчылуы һәм Бөек Ватан сугышы башлануы хакындагы хәбәр килүе күрсәтелә. Әсәрдәге Мәрьям абыстай образына нәфис фильмда Мәрьям түти дигән үзгәреш кертелгән. Татарда «абыстай» дип эндәшү элек-электән олылау, ихтирам билгесе дә булып саналганлыгын искәртеп үтик. Киносценарийда Ә. Еники болай тасвирлый: «Мәрьям абыстай (карчыкның исеме шулай) сискәнеп-селкенеп куя» [5, б. 2]. Ә. Еникинең совет чорында язылган хикәядә абыстай дип эндәшүне калдыруы – татар гаиләсендә хатын-кызга ихтирамлы мөнәсәбәтнең борынгыдан килгән гадәт булуын ассызыклавы ул. Безнең карашка, «түти» дип үзгәртү Ә. Еники өслүбеннән, хәтта фильмның фикер җебеннән беркадәр читенү кебек тоела.

Нәфис фильмда игътибарны авыл тормышының нәкъ Ә. Еники киносценариендагыча бирелүе җәлеп итә: «Авыл тын, буш, урамында бер кеше заты күренми. Яше-карты барсы да эштә. Каяндыр ерактан печән чапкычның такылдавы тонык кына ишетелеп куйгалый» [5, б. 1]. Ләкин Галимҗан абзыйның авыл читендәге өе Ә. Еники сурәтләгән өйдән бик аерыла. Фильмдагы зур, иркен өй сурәте, төзек капка-койма, каралты-кура Бөек Ватан сугышы чоры авылы күренешеннән алып китә. Ә. Еники тәкъдим иткән киносценарийда өй сурәте мондый: «Авыл читендәге кечкенә өйнең тәрәзәсендә карчык шәүләсе күренә. Ул тын гына ачык кырга карап тора. Каршыда, авылдан бер-ике чакрым читтә, сырт буйлап авыл юлы уза. Аның карт юкәләр ышыгында

утырган кечкенә кызыл кирпеч станциясе һәм сарыга буялган каралтылары күренә...» [5, б. 1].

Ә. Зарипов тәкъдим иткән Бөек Ватан сугышы фаҗигаләре турындагы фильмда реаль тарихи кадрлардан фрагментларның әледән-әле кабатланып торуы фильмның ышандыру көчен арттыра. Мисалга, 2024 нче елгы «823 нче километр» фильмына документаль кадрларны файдалану җитенкерәми.

Ә. Еникинең сугыш турындагы хикәяләрендә поезд, тимер юл, станция кебек әдәби урынны билгеләүче топослар әһәмиятле роль уйный. Ә. Зарипов биредә язучы өчен әһәмиятле булган хронотоп аша мәгънә ирештерү юлын саклый, вакыт та, урын да еш алышынып тора. «Хәтәр һәм хәтер» фильмында перцептуаль хронотоп белән концептуаль хронотоп кисешүе (Гомәрне туган йортында көтүләре, аның сугыш кырында дошман кул астында булып та, исән калуы, аның нәсел дәвамчысы – улы булуы хакында ачыклану) күзәтелә. Бу күренеш уйдырма катламны киңәйтә, фильмның идеясен укучыга төрле образлар аша бирүдә ярдәм итә. Нәфис фильмда сугыш башланган тарихи вакыт – җәй – берничә тапкыр алышына. Гомәрне озату вакыйгасы – көз, Гомәрнең кайтып күренү вакыйгасы – иртә яз, үлем хәбәре килү – көз белән кыш алышыну кебек вакыт образлары аша символлаштырыла. Бу урында әйтергә кирәк: Ә. Еникинең туган авылы Югары Каргалы башында шулай ук поезд юлы үтә һәм авылдан берникадәр югарырак станция урнашкан. Ә. Еники үскән Дәүләкән авылыннан ерак түгел шулай ук Бүздәк тимер юл станциясе бар. Шуңа күрә язучы иҗатында да бу әдәби урын еш очрый һәм символик мәгънәгә ия. Фильмдагы эшелон сурәте дә Ә. Еникинең әсәрләрендәгечә калдырылган. «Бер генә сәгатькә» киносценариенда эшелон сурәте түбәндәгечә: «Аның каршында озын эшелон тора. Юл буенда әрле-бирле солдатлар йөриләр яки бер урында күмәкләшеп, сөйләшеп торалар. Эшелон тиздән кузгалырга тиеш – паровоз инде җанланып, ак төтеннәрен чыгара. Гомәр эти-әнисен ияртеп, үз вагоны янына килә» [5, б. 19].

«Бер генә сәгатькә» хикәясе дә, язучының үз истәлекләренә караганда, аның Нигъмәтулла дәдәкае турындагы хатирәсенә бәйле төстә иҗат ителгән. «Соңгы китап» (1987) мемуарларында «Бер генә сәгатькә» хикәясе сюжетының нигезенә яткан бу вакыйганы язучы болай сурәтли: «Унҗиденче елның кара көзендә булса кирәк, безнең авыл турысыннан фронт ташлап кайтучы солдатлар төялгән эшелоннар үтә башлый. Шундый эшелоннарның берсеннән татар солдатлары: «Сезнең авылныкы Нигъмәтулла кайта-а! Арттагы эшелонда, хәбәр итәргә кушты-ы!» дип кычкырып узганнар, имеш. Кемдер шуны ишетеп, чаба-чаба әбекайларга килеп әйткән икән. Билгеле инде, өйдәгеләр бу яшендәй ялтырап киткән хәбәрдән башта сискәнеп-каушап, аннары чиксез шатланып, дәррәү аякка басканнар. Шунда ук ат җиктереп, якын туганнардан берәүне (Рәхмәтулла абзыйны булса кирәк) Бүздәккә чаптырганнар (ул заманда поездлар Каргалыга туктамыйлар иде), үзләре тиз генә мунча якканнар, тәкә суйганнар. Ләкин ул көнне, тәмам караңгы төшкәч, тирләп беткән ат буш кайткан... Өмет дигәнең гаҗәп нык, үҗәт нәрсә ул! Икенче көнне, өченче, дүртенче көнне дә атны Бүздәккә куалар, эшелоннар да һаман уза торалар, әмма ләкин Нигъмәтуллабыз юк та юк! Өйдәгеләр, бичаралар, аптырап, гаҗиз булып, саргаеп бер атна, ике атна, хәтта бер ай көтеп карыйлар, аннары инде килеп әйтүче ялгыш ишеткәндер дип, акренләп өметләрен өзәләр. Әбекай озак-озак кына намазлык өстендә утыра, ә Мәдинә җиңгәчәй казан янында тавышын чыгармыйча гына ачы яшьләрен коя...» [8, б. 34-35]. Шушы тетрәндергеч вакыйга язучыны 1944 нче елда «Бер генә сәгатькә» хикәясен, соңрак шул исемдәге киносценарийны язарга этәргеч бирә. Бу – язучының тормыш тәҗрибәсе, ул аның яхшы таныш булган кешеләренең – туганнарының биографиясеннән тукылган. Ә. Зарипов Ә. Еникинең Нигъмәтулла дәдәкаеның прототиплары – «Бер генә сәгатькә» хикәясендәге Гомәр, «Тауларга карап» хикәясендәге Батырҗан, «Кунакчыл дошман»дагы Хәким, «Ана һәм кыз»дагы Хәсән образларында бирелгән сыйфатларны төп персонаж Гомәр образында гомумиләштерә.

Ана кешенең улларын сугыштан көтү киеренкелеге шулай ук нәкъ Еникидәгечә сурәтләнә. Фильмда төпчеге кигән, аныкы булган әйберләргә әни кешенең кул да тидертмәве, улының яраткан хезмәт коралы – чалгыга башкаларны якын китермәве күрсәтелә. Мәрьям түти персонажын тудырган Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Фирдәвес Хәйруллина осталыгы аерым игътибарга лаек. Актрисаның тавыш тембры,

үз-үзен тотышы, катлаулы хис-кичерешләрне үтемле җиткерүе нәкъ менә Ә. Еники иҗат иткән Мәрьям абыстай образына тулаем туры килә. Ләкин Галимҗан абзый образын уйнаган Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакиров персонажы Ә. Еники иҗат иткән Галимҗан абзый образына тәңгәл түгел. «Бер генә сәгатькә» киносценариенда Галимҗан абзый – сабыр, җитди, басынкы булуы белән якыннарын тынычландыручы персонаж. Бередә шулай ук Ә. Еникинең образны морзалар нәселенә караган бабасыннан алып язуын искәртергә кирәк. Шулай ук әдип Галимҗан абзый образы аша автор фикерен җиткерә, укучыны көтелмәгән шартларда тыныч, сабыр булырга, бирешмәскә өнди. Ә. Шакиров Галимҗан абзый персонажына ярсулык, кызулык, урыны белән шуклык өсти. Шулай да Ә. Зариповның Галимҗан абзый персонажы уңышсыз дип әйтеп булмый, бары тик аңа башка функция йөкләнә. Ул – гаиләсе өчен җаваплылык тоючы ата образы һәм дүрт улын сугышка озаткан ата кешенең гаиләсен ничек якларга белмичә каударлануы табигый, ышандыра. Еникинең Галимҗан абзый образы башкарган вазифаны фильмда Локман карт персонажы үз өстенә ала. Локман карт Ә. Еникинең «Тауларга карап» хикәясеннән алына, ул аксакал архетибына тартым. Мәгълүм булганча, әдипнең иҗатында аксакал архетибы нәселнең киләчәге турында кайгыртучы образ буларак гәүдәләнеш таба («Әйтелмәгән васыять»тә Миңлебай карт). Фильмдагы Локманда әдипнең «Матурлык» хикәясеннән алынган Бәдретдиннең бабасы сыйфатлары да бар. Авыру карт Локман аз сүзле, саташуы – асылда фаҗигане алдан кисәтүе. Мисалга, Гомәрнең кайтмаячагын Ә. Зарипов Локманнан әйттерә, токым калдыру кирәклеген дә Гомәргә, кайткач, бабасы искәртә. Галя – Галия алып кайткан Василны шулай ук капка төбендә Локман карт каршы ала. Бу – Ә. Зариповның табышы, чөнки Ә. Еники иҗатының бер мотивы – кавемнең, нәсел-токымның дәвамчанлыгы турындагы идея. Ә. Еники әсәрләрендәге нәсел дәвамчылары аз сүзле, тирән фикерле, асыл татар ирләре. Ә. Зарипов Ә. Еники үз иҗаты аша үткәрергә теләгән төп идеяләрнең берсен фильмның нигезенә салып җиткерүгә ирешә.

Төп персонаж Гомәрне ачарга Локман карт, Василий, Талип, Шәрифулла персонажлары ярдәм итә. Персонажның исемен Гомәр дип сайлау да ышандыра, чөнки фильмга төп нигез итеп язучының «Бер генә сәгатькә» хикәясе һәм киносценарие алынганлыгы аңлашыла. Әхтәм Зариповның Гомәре – Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисты, ул вакытта әле яшь актер Фәнис Җиһаншаның уңышы ул. Әйтергә кирәк, Ф. Җиһанша Ә. Еники персонажларын бүгенгәчә яратып сәхнәләштерә, хикәяләрен аудиоформатта яздыруда даими катнаша. Ф. Җиһаншаның персонажы Ватанын өзелеп сөюче, туган җиренә беткәнче тугры булган яшь солдат буларак уйланылган. Ә. Зарипов ватанпәрвәрлек турындагы фикерләрне һәрдаим Гомәр теле белән әйттерә. Гомәр, Василий персонажыннан аермалы буларак, авыр шартларда куркып калмый, Талиптан аермалы буларак, кызу канлы, васвәсәгә бирелүчән түгел. Галя өенә килгәч тә Гомәр, ярасын бәйләтүгә, взводы янына ашыгуын әйтә. Ф. Җиһанша ана-бала мөнәсәбәтләрен дә нечкә, үтемле итеп тәкъдим итүгә ирешә. Персонажның урыны-урыны белән беркатлы яңгыраган репликалары, катлаулы ситуацияләрдә югалып калуы да талантлы актер тарафыннан үтә дә табигый җиткерелә.

Ә. Еники фикерләрен Ә. Зариповның нәфис фильмында Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗанов башкарган Шәрифулла персонажы уңышлы җиткерә. Гомәр калдырган портсигарны да режиссер Шәрифуллага тоттыра. Бу урында портсигарга соңгы өмет дип сызланып карап торган Мәрьям түти, Галимҗан абзый, Шәрифулла, Камилә килен фаҗигасе гаҗәеп тирән җиткерелә. Шәрифулланың исереклегенә татар иренең әрнүләре, сызланулары салына, Илдус Әхмәтҗановның кабатланмас уйнавы тамашачыны тетрәндерә.

Гомәр образын ачарга ярдәм иткән Василий образы үзгәрәк. Ул дошманнар янында үз дәрәҗәсен югалтмый, алар белән табигый һәм җиңел сөйләшә. Әмма Василий особеслар хөкеменнән куркып кала, шул рәвешле, фильмга, хикәя сюжетыннан аермалы буларак, дезертирлык проблемасы кертелә.

Әйтергә кирәк, Ә. Зарипов бу өлештә «Кунакчыл дошман» хикәясен тулаем диярлек урнаштыра. Ул фильмның икенче сериясе итеп уйланылган. Ә. Еники хикәясендә тасвирланган барлык сюжет элементлары, диалоглар нәфис фильмда шул вариантта тасвирлана һәм үстерелә, киңәйтелә. Фильмда тамашачыны ышандыру көчен арттыру максатыннан дошман

офицерын татар телендә түгел, ә алман телендә сөйләштереп, аның белән рус телле тәрҗемәче булуын, ким дигәндә, рус телендә акцент белән сөйләшкән офицер итеп, ә татар теленә тәрҗемәне субтитрлар ярдәмендә һәм кадр арты тавышы белән җиткерү ышанычлырак булыр иде кебек. Чөнки дошман офицерын татар телендә сөйләштерү тамашачыны дошман офицерын илен саткан татар кешесе буларак кабул итүгә урын калдыра.

Талип персонажы да хикәядәгедән аерыла, асылда ул ярсулыгы, сабырсызлыгы аркасында үзен һәлак иткән солдат образы буларак гомумиләштерелә. Әмма Ә. Еники һәм Ә. Зарипов төп фикерне җиткерүдә бу образны оста файдаланалар.

Шул рәвешле, Гомәр егетләр белән чагыштырганда кыюрак, зирәгрәк булып чыга. Ул үз дусларына тугры. Галиягә алар турында сөйләгән булса кирәк, хатын Гомәрнең улына Васил дип исем бирә. Бу мотив «Тауларга карап» хикәясеннән алына, ләкин үзгәртелә, үстерелә. Ә. Зарипов язучының әлеге әсәрендәге Локман карт образы аша токым калдыру идеясен җиткерә. «Тауларга карап» хикәясендә тегермәнче Локман бабайның оныгы Батырҗанның өч яшьлек улы Газизҗанның кайтарылуы турында әйтелә. Ә. Еникинең: «Тормыш бетми, һаман, һаман дәвам итә», – дигән фикере нәфис фильмда үстерелә [9, б. 105].

Фильмда ярдәмче образлардан Заһидә һәм Галя – Галия образлары үзенчәлекле. Заһидә нәкъ «Бер генә сәгатькә» хикәясендәгечә калдырылган. Галя – Галия персонажын уйнаучы Татарстанның атказанган һәм халык артисты Зөлфия Вәлиева – Латыйпова һәм аның әбисе персонажын уйнаучы Татарстанның халык артисты Халимә Искәндәрова дошманнар чолганышында калган хатын-кызларның язмышын аеруча тетрәндергеч итеп җиткерүгә ирешәләр. Бер яктан, Галиянең Гомәргә ашкынулы-дәртле ташлануы тамашачыда сорау тудырырга мөмкин. Татар егете өчен мондый күренеш ят. Ф. Җиһанша моны да бик табигый җиткерә. З. Вәлиева персонажы да азгынлыктан өстен. Дошманның гаиләләрне вәхшиләрчә кыруын, хатын-кызларны кимсетүен Ә. Зарипов З. Вәлиева персонажының әрнүләренә һәм Х. Искәндәрова персонажының тирән сызлануларына сала. Барысы да Еникичә төгәл, гади, табигый, аңлаешлы. Тамашачыда Ә. Еникинең Гомәре үзгәртелгән дигән фикер туарга да мөмкин. Гомәр Заһидәгә хыянәт итәме? Ләкин Ә. Зарипов Галя – Галия образына нәсел калдыру җаваплылыгын йөкли: «Мине я бүген, я иртәгә барыбер дошманнар көчләячәкләр, ал мине, татар егете!» – ди ул. Әтисе, әнисе, сеңлесе үтерелгәннән соң шашынып калудан олыгайган, дошманнар тарафыннан мәсхәрәләнгән 17 яшьлек рус кызы әбисенең итәгенә ятып өзгәләнә. Ә. Зарипов биредә дә Ә. Еникинең сугыш турындагы хикәяләрендәге идеясен үстерә: яшәү барыбер үлемнән көчлерәк, токым калдыру үлемне җиңә. Димәк, иҗатташлар кешене көтелмәгән кискен ситуацияләрдә сурәтләп, гомумкешелек фәлсәфәсен милли гомумиләштерү ноктасында чишәләр. Бу урында Татарстанның атказанган артисткасы Әнисә Сабирова уйнаган Камилә килен образы аша җиткерелгән Гомәрнең үлеме турындагы хәбәр – асылда Ә. Еникинең «Ана һәм кыз» хикәясеннән алынган мотивның кабатлануы. Рәхилә кебек Камилә дә анага баласының үлеме турындагы хәбәрне ничек тә әйтмәскә тырыша. Ә. Зарипов биредә шулай ук Ә. Еники фикерен үстерә. Сугыш шартларында урыс кызына татар токымын тәрбияләү бурычын йөкләү, татар кешесенең гаҗизлектән аракыга үрелүе һәм бала үлемен анага хәбәр итәргә кыймау – һәммәсе табигый. Үлемгә тиң мизгелдә яшәеш кыйммәтләре буларак нәкъ менә милли кыйммәтләр калка. Гомәр Галяга татар исеме куша, үзе дә сизмәстән татар токымын дәвам итәргә васыять әйтеп калдыра. Үз чиратында Локман карт бу баланы нәсел дәвамчысы итеп кабул итә. Димәк, Ә. Зарипов Ә. Еники тәкъдим иткән милли яшәеш фәлсәфәсенә тугры кала.

Фильмда дошман офицерын Татарстанның атказанган артисты Илтөзәр Мөхәммәтгалиев җиренә җиткереп, ышандырып уйный. Ә. Еники текстындагыча, «үлек битле, мәкерле карашлы», шул ук вакытта салкынлык бөркелеп торган персонажның сөйләме үтә дә табигый. Гомумән, актер уены осталыгы, ут кую, бизәлеш аша фильмда совет солдатларының дошманнар кулында калуы җанлы итеп күрсәтүгә ирешелә.

Режиссер идеясе язучы идеясе белән тәңгәл килә. «Ә. Еники кеше психологиясен, холкын, аның аерым көтелмәгән ситуацияләрдә үзен тотышын сурәтләү үзәгенә куя һәм шулар аша кешелеккә хас универсаль кыйммәтләрне аерып чыгу омтылышы ясый» [9, 158 б.]. Ә. Зарипов Ә. Еники хикәяләрендәге шәхеснең олы җанлылыгы, кешелеклелеге идеясен алга куя,

чордашлар Ә. Зарипов белән Ә. Еники яшәеш кыйммәтләре дип нәсел, дәвам, мәхәббәтне аерып чыгаралар.

Композицион яктан фильмда хикәяләрнең бер-берсенә ялганып китүе шактый уңышлы оештырылган. Фильмда Ә. Еники хикәяләренең стилистик яктан төгәл булуы сәхнәдә бу әсәрләрне бер чылбырга тезеп күрсәтү эшен шактый җайлаштыра. Бу җәһәттән, бүгенге көндә татар театрлары сәхнәләрендә барган Ә. Еники хикәләрендәге мотивлар нигезендә куелган спектакльләр дә шуны дәлилли. Мәсәлән, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры труппасы репертуарында Ә. Еникинең «Рәшә» повесте буенча шул исемдәге спектакльдә (режиссер һәм инсценировка авторы Айдар Җәббаров) повестьтан тыш «Бер генә сәгатькә» хикәясе мотивлары да кулланыла. Хикәя бу спектакль структурасына шулай ук шактый отышлы кертелгән: «Рәшә» повестенда сурәтләнгән гастрольләрдә йөрүче артистлар язучының нәкъ шушы әсәрен сәхнәләштерә. К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында «Сезне Ватан онытмас!» спектакле (режиссеры Зөлфәт Закиров, инсценировка авторы Шамил Фәрхетдинов), шулай ук язучының «Бала», «Кем җырлады?», «Ана һәм кыз» хикәяләре нигезендә эшләнгән. Әлмәт Татар дәүләт драма театрындагы «Тормыш корабы» спектакле (режиссеры Гүзәл Акбердина, инсценировка авторы Фәридә Исмәгыйлева) язучының «Шаяру», «Тынычлану», «Төнге тамчылар», «Матурлык», «Бер сүз», «Мандарин сатучы» хикәяләрен нигез итеп алган. Шул рәвешле, соңгы елларда Ә. Еники хикәяләрен бербөтен күреп, туплап, аларны тулы бер композицион структурага җыю омтылышы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхтәм Зариповның «Хәтәр һәм хәтер» фильмыннан башланган дияргә җирлек бар.

## Төп нәтиҗәләр

Әмирхан Еники прозасы татар кино сәнгате аша тәүге тапкыр тамашачыга 2000-2001 нче елларда «Хәтәр һәм хәтер» нәфис фильмы буларак тәкъдим ителә. Бөек Ватан сугышы темасына караган әлеге фильм Ә. Еникинең 1944-1948 еллар аралыгында язылган өч хикәясен – «Бер генә сәгатькә», «Кунакчыл дошман», «Тауларга карап» үз эченә ала. Заманында психехник белгечлеге алган язучыга кино сәнгате таныш өлкә. 1970 нче елда әдип «Бер генә сәгатькә» исемле үзе эшләгән киносценарийны «Азат хатын» журналына тәкъдим итә.

Ә. Зарипов Ә. Еникинең сугыш турындагы хикәяләрендәге идеяләрне үстерә. Яшәүнең үлемнән көчлерәк булуын раслый, милли яшәеш кыйммәтләре буларак нәсел, дәвам, мәхәббәтне аерып чыгара. Телевизион фильмда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының иң көчле составы катнаша: Ф. Хәйруллина, Х. Искәндәрова, Ә. Шакиров, И. Әхмәтҗанов, И. Мөхәммәтгалиев, Ф. Җиһанша һ. б. уены фильмның уңышын тәэмин итә.

## Йомгак

Татар кино сәнгатендә Ә. Еникинең әсәрләре урын алуы классик текстларны кино сәнгате теленә күчерү ихтыяҗы барлыгы белән билгеләнә. Әмирхан Еники прозасы – кино сәнгатенә күчерү өчен катлаулы, үзенчәлекле материал. Режиссер һәм инсценировка авторлары Ә. Еники иҗатын тулаем өйрәнеп, әдипнең автобиографик повестьларын күздән кичереп, кино сәнгатенә күчерү эшенә алынырга тиеш. Әдипнең хикәяләрен нәфис фильм итеп эшләгәндә язучы әсәрләренең телен, стилен, идея-эстетик үзенчәлекләрен саклау зарур. Ә. Зарипов «Хәтәр һәм хәтер» фильмын эшләп, Ә. Еники әсәрләрен кино сәнгате аша җиткерүнең матур үрнәген күрсәтте. Режиссер Ә. Еники үткәрергә теләгән милли яшәеш фәлсәфәсен уңышлы тәкъдим итүгә ирешә алды.

Статья написана и опубликована при финансовой поддержке РНФ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта «Проведение фундаментальных научных исследований и поисковых научных исследований малыми отдельными научными группами» (региональный конкурс)» № 24-28-20211

**Әдәбият**

1. *Гайнуллина Г.Р.* Татар театры сәхнәсендә Ә. Еники әсәрләре. Татарика. 2023. Т. 20. №1. Б.126-148.

2. *Хәйруллина И.* 823 нче километр: «Әгәр дә бу фильмны Әмирхан ага караса, ул дәгъва белдерер иде...». Интертат, 24.02.2024. – URL: https://intertat.tatar/news/823nce-kilometr-agar-da-bu-filmny-amirxan-aga-karasa-ul-dagva-belderer-ide-5864448 – мөрәҗәгать итү вакыты: 20.09.2025.

3. *Хабутдинов А., Хабутдинова М.* Военные дневники татарских писателей: путь к читателю сквозь рамки цензуры // Филология и культура.

Philology and Culture. 2025. No 2 (80). С. 204–211. DOI: 10.26907/2782-4756-2025-80-2-204-21

4. *Аксой Г.Г., Хабутдинова М.М.* Татарский телетеатр в зеркале общественного мнения. Tatarica. 2022. 18(1). С. 97-115. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2022-18-1-97-115

5. Архив НМ РТ КП-18968-27 Ә. Еники кулъязмасы. Бер генә сәгатькә: киносценарий. 1970. 23 б.

6. *Галимуллин Ф.Г.* Проблема отражения русско-татарских литературных взаимодействий в периодике 1920-1930-х годов. // Филолгия и культура. 2012. № 2(28). С.196-198.

7. *Еники Ә.* Бер генә сәгатькә: (киносценарий) // Азат хатын. 1970. № 5. Б. 12–15.

8. *Еники Ә.* Соңгы китап. Истәлекләр. Казан: Татар кит. нәшр., 1987. 504 б.

9. *Еники Ә.* Әсәрләр: 3 томда / Әмирхан Еники (төз. Г.Р. Гайнуллина). Казан: Татар кит. нәшр., 2019. Б. 82-105.

10. *Заһидуллина Д.Ф.* 1960-1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. Казан: Татар кит. нәшр., 2015. 383 б.

# РЕЦЕПЦИЯ ПРОЗЫ А. ЕНИКИ В ТАТАРСКОМ КИНЕМАТОГРАФЕ (НА ПРИМЕРЕ ТЕЛЕФИЛЬМА «ХӘТӘР ҺӘМ ХӘТЕР» («ОПАСНОСТЬ И ПАМЯТЬ»))

**Светлана Фагимовна Мухаммадиева**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
gsf16@mail.ru.

**Гульфия Расиловна Гайнуллина**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
gulfiarasilevna@mail.ru.

В статье изучаются особеннности экранизации прозы народного писателя Республики Татарстан, лауреата Государственной премии ТАССР им Г. Тукая Амирхана Еники (1909–2000). Первым к ней обратился режиссер Ахтям Зарипов. В 2000–2001 гг. в киностудии «Илһамият» был создан телефильм «Хәтәр һәм хәтер» по мотивам рассказов писателя «Бер генә сәгатькә» («Только на час", 1944), «Кунакчыл дошман» («Гостепреимный враг», 1945), «Тауларга карап» («Вглядываясь в горы», 1948). В 2024 г. по мотивам рассказов Амирхана Еники «Матурлык» («Красота», 1964), «Бер генә сәгатькә» («Только на час», 1944), «Кем җырлады?» («Кто пел?», 1956) был снят полнометражный фильм «823нче километр» («823 км», автор сценария Валерия Байкеева, режиссеры Ирек Хафизов, Амир Галиаскаров). В работе проделан сравнительно-сопоставительный анализ синопсиса Амирхана Еники со сценарием и кинотекстом Ахтяма Зарипова. В ходе исследования выявлены особенности сюжетного параллелизма, художественные средства наглядности и описательности, роль актеров в раскрытии авторского и режиссерского замысла и др.

**Ключевые слова**: татарская литература, татарская проза, татарское кино, Амирхан Еники, Ахтям Зарипов

**Для цитирования**: Мухаммадиева С. Ф., Гайнуллина Г. Р. Рецепция прозы А. Еники в татарском кинематографе (на примере телефильма «Хәтәр һәм хәтер» («Опасность и память»)) // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 96–109. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-96-109